# КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

9 декабрь, 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

**тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау; (урам яктыртуны карап тоту, урам яктырту өчен комплектлаучы яктырткычлар, энергия саклаучы лампалар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);**

**су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суыртү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суыртү манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);**

**җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Әсән-Елга авылында чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал, буяулар сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;

**янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (Әсән-Елга авылында янгын гидрантлары, инвентарь, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, материал ташу һәм башка эш төрләре);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (вак таш сатып алу, юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Әсән-Елга авылының Яр буе, Яшьләр урамында юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре)

(Яр буе урамына асфальт җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

(Әсән-Елга авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, су үткәргеч торба сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

**торак пункт территориясен төзекләндерү** (җирлек территориясен төзекләндерү); (агачларны һәм куакларны кисү, тәпләү һәм санитар эшкәртү); (спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру); (төзелеш материаллары сатып алу, халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

**традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү** (зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, агачларны кисү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков

ОГРН 1021607752979 ИНН 1623001928